РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ МЕШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422062, Республика Татарстан, Сабинский район, п.Лесхоз, ул. Кукморская, 2а
тел. (84362) 44-2-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422062, Татарстан Республикасы, Саба районы, Лесхоз бистәсе, Кукмара урамы, 2а йорт
тел. (84362) 44-2-19

e-mail: Mesh.sab@tatar.ru

24.09.2018 №20

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында” 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Мишә авыл җирлеге Советының 15.09.2018 №19 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Мишә авыл җирлеге башкарма комитетының 15.09.2018 №25 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Лесхоз бистәсендә яр буйларын төзекләндерү;
- Сабабаш торак пункты зиратларын һәм аларның тирәләрен карап тоту.

ӘЙЕ ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Мишә авыл җирлеге башлыгы А.Х.Гатиятуллин